# 10 нчы сыйныфта татар теленнән язма эшләр

1. ***Тикшерү диктанты***

**Рәхмәт, Тормыш!**

Рәхмәт сиңа, кояш! Түп-түгәрәк булып тау артыннан көлә-көлә килеп чыкканың өчен. Көлүен бар дөньяга нур булып бөркелә. Сиңа үрелеп, гөлләр булып үсәбез, синдә наз, синдә яшәү, синдә шатлык.

Рәхмәт сиңа, җил! Ачык тәрәзәмнең челтәр пәрдәләрен җилфердәтеп, чәчләремә йомшак кагылып, күңелемне җилләндергәнең өчен. Рәхмәт, җилкәй, бакчамдагы шомырт, сирень чәчәкләренең хуш исләрен миңа бүләк иткәнең өчен.

Рәхмәт сезгә, Туган җирем, болыннарым, тугайларым, кырларым! Рәхмәт сезгә, тәмле сулы чишмәләрем! Бер йотым суыгызда — мең дәва.

Рәхмәт, Тормыш! Сынауларыңа сынмаслык рухи көч биргәнең өчен. Матурлыкны күреп, яхшылыкны тоеп яшәү сәләтемнән аермавың очен. Кыенлыклар килгәндә, дулкын булып ярларга кагам, кош булып кыяга бәреләм, давыл булып шашам. Ә шулай да Кеше булып калу матуррак.

Рәхмәт, Тормыш! Кеше булып яшәвемне таләп иткәнең өчен. *(115 сүз.) (К. Шәфыйковадан)*

**Биремнәр.**

1.Тексттан ясалма сүзләрне табып, асларына сызарга.

2.*Болыннарым* сүзендәге сузык авазларга характеристика бирергә.

2. ***Изложение***

**Дуслык ничек туа?**

Зур панельле йортлар сала башлагач, ай-һай кызуга китте төзүчеләрнең эшләре. Печән кибәне хәтле экскаваторларның, яман уылдап, әреме-куагы, ташы-ние белән җирне умыртырга тотынуы була, машина-машина стена,

йөге-йөге белән ишек-тәрәзәләр, идән-түшәмнәр китереп аударалар да, әкияттәге батыр шикелле, күз ачып йомганчы, биш-алты катлы йортларны утырталар да куялар, утырталар да куялар. Бер-бер аралы тезелеп кенә тора яңа урамнар. Көзен Камилләр Беренче Аркылы урамга күчеп килгәннәр иде. Хәзер андый урамнар җидәү. Тиз генә исем табып бетерүе дә читендер шул, барысына да Аркылы дип кушканнар.

Беренче Аркылы урамнан җиденче сыйныфта ике генә малай укый. Аларның берсе — Камил, түп-түгәрәк битле, кьсынкырак кара күзле, таза гәүдәле, авыр хәрәкәтле укучы, икенчесе — аның партадаш дусты Алик. Ул да гәүдәгә артык зур түгел, тик бөтерчек шикелле җитез, һәрвакыт каядыр ашыга, нәрсәгәдер омтыла, кызу-кызу сөйләшә, иптәше бер сүз әйткәнче, ул унны ычкындырып өлгерә. Озын керфекләр астына яшеренгән зур сөрмәле күзләре генә сабыр, уйчан һәм малайның хәрәкәтчән, җыйнак гәүдәсенә ничектер ят булып тоела. Камилләр дә, Аликлар да бу урамга бер үк көнне күчеп килделәр. Бер үк йортның бер катына да туры килделәр әле, җитмәсә. Ишекләре кара-каршы гына тора. Беренче көнне үк дуслаштылар алар.

Бишенче урам малайлары Камалләрнең авызына гына карап тора: соңрак килгәнгәдер инде, алар кыюсызрак әле, кунак шикелле, әдәпле тоталар үзләрен.

Шулай да озак бармады бу хәл. Кышкы каникулдан соң аларның сыйныфына тагын бер малай килде. Озын буйлы, киң җилкәле. Беләк һәм күкрәп мускуллары, гимнастеркасын тартып, тыгызланып тора. Килгән көнендә үк белделәр Камилләр: Фоат атлы бу малай җәен-кышын йөзү бассейнына йөри икән. Укучылар арасында йөзү буенча республика чемпионы да үзе.

Тышкы кыяфәте белән үк башкалардан аерылып торган Фоат, атна-ун көн дә үтмәде, сыйныфны үз кулына алды да бетерде. Хәер, Камил белән-Алик беренчелек өчен бәхәсләшергә уйлап та карамадылар. Чемпион хәтле чемпион белән дуслашу аларның үзләре өчен дә кызык иде.

Ә Фоат чыннан да шәп малай булып чыкты ул. Иң элек, Камил белән

Алик шикелле тererәк малайларны җыеп, йөзүчеләр түгәрәге оештырды. Йөзүчеләр дип аны Фоат белән шул түгәрәккә йөргән малайлар гына чын күңелдән әйтә инде. Ә калганнары ачулары килгәндә, *я* үртәргә кирәк булганда шулай диләр. Чөнки Аликларның түгәрәккә йөри башлаганнан бирле бер тамчы да су күргәннәре юк әле. Физкультура залына алып керә дә Фоат аларны, идәнгә яткырып, йөзү хәрәкәтләре ясарга өйрәтә, я җыелган саен гимнастика эшләтеп йөдәтә. Дөрес инде анысы, түгәрәк утырышлары шәһәрнең йөзү бассейнында үтсә, мең кат әйбәт булыр иде дә бит. Фоат әйтә: «Анда йөрүчеләр болай да бик күп, алдан өйрәнеп барсак, үзебез өчен яхшырак булыр»,— ди. Түзәләр инде Камилләр. Сыйныфташларының үртәүләренә дә, бертөрлелеге белән туйдырып бетергән гимнастика алымнарына да түзәләр. Аның каравы, язга чыккач, йөзү ярышлары башланып китсә, үртәп теңкәгә тиючеләр үзләре йөрерләр әле йөзүчеләр артыннан.

Тик бер ягы җитми Фоатның, грамматика белән дус түгел. Шулай да бирешергә чамасы юк малайның. Теше-тырнагы белән чытырдатып ябышкан ул дөрес язу кагыйдәләренә, тартышыпмы-тартыша. Үзенең генә көче җитмәгәч, иптәшләренең ярдәменә таянырга булды ул. (415 сүз)

*Л. Ихсановадан*

3. ***Фонетика темасына контроль диктант***

**Бөек шагыйрь авылында**

Бөек шагыйрь Габдулла Тукайның туган авылына мәхәббәте чиксез зур була. Бу авылның челтерәп аккан чишмәләре, яшел чирәмле урамнары, ерактан ук күренеп торган басу юллары — барысы да газиз, барысы да шагыйрь күңелендә тирән уелып калган. Шуның өчен ул аны сагынып искә ала:

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,

Шуңа күрә сөям җаным, тәнем белән, — ди.

Менә без шагыйрьнең туган авылы Кушлавычта! Тукай әйткәнчә, авыл тау башына салынган. Төз һәм матур йортлары белән ул ерактан ук күңелне үзенә тартып тора. Элекке замандагы салам түбәле, төртсәң аварга торган иске өйләр урынында шулай мәһабәт булып калкып чыккан бу йортлар!

Авылның хезмәт сөюче кешеләре Тукайны тирән хөрмәт белән искә алалар. Алар үз колхозларын Тукай исеме белән атап йөртәләр, авыл китапханәсенә дә аның исемен биргәннәр.

Шул китапханә каршында гына сөекле шагыйребезнең һәйкәле бар.

Әсәрләре якты маяк булып балкыган шагыйребез менә шушы авылда туган, сабый чагында ук кимсетелүләр һәм ятимлекләрне дә шушы авылда кичергән.

Без дә Тукайны яратабыз, аның шигырьләрен кызыксынып укыйбыз. (172 сүз) *(С.Шакирдан)*

**Бирем.**

***Авыл, шагыйрь*** **сүзләренә фонетик анализ ясарга.**

**4.** ***Контроль изложение***

## Кызару

Җәйге каникулны да бергә үткәрергә уйлап, мин Ногманны үзебезнең авылга алып китәргә булдым. Башта ул бераз уңайсызланып торса да, соңыннан риза булды. Зачетларны да уңышлы биреп тынычланып калгач, бик күтәренке күңел белән юлга чыктык. Без төшәсе станциягә килеп җиткәнче, андый-мондый нәрсә булмады. Вагоннан төшкәч тә, Ногманны багажлар янына утырттым да ат эзләргә киттем, чөнки безнең авылга барып җитәргә егерме чакрымлап бар иде әле. Станциянең аргы ягына чыксам, бер ат әкрен генә юыртып китеп бара. Аны кычкырып туктаттым, янына бардым. Арбада ак яулыгын артка чөеп бәйләгән, кара күлмәк өстенә күк төстәге атланмалы алъяпкыч кигән бер хатын утыра. Карыйм — моның тут баскан битләрен, кап-кара күзләрен кайдадыр күреп калган кебек тоям. Кинәт исемә

Ногманның акчасы югалган көнне безнең уртадан капчык күтәреп үтеп киткән хатын килеп төште. Нинди кызыклы очрашу. Аңа карап тукталып тормадым, аның кайсы авылга кайтуын сорадым. Аның юлы нәкъ безнең авыл аркылы үтәргә тиеш икән, ул безнең күрше авыл хатыны булып чыкты. Хатын безне утыртып алып кайтырга башта риза булмады. Атка правление рөхсәтеннән башка беркемне дә утыртып йөрергә хакы юклыгын әйтте. Ләкин, үтенеп сорагач, правлениегә барып, километр исәбеннән куелган бәядән хак түләү шарты белән генә утыртырга мөмкинлекне әйтте. Мин, акча түләү өчен күрше авылга барып йөрү кыенлыгын күз алдында тотып, акчаны аның үзенә генә тәкъдим итеп карадым. Ләкин ул бик кырку гына тавыш белән:

— Ничек инде ул, куелган тәртипне бозарга кушасызмыни, акча минем кесәдә калсын дисезмени? Мондый «яхшылык» өчен сезгә бик рәхмәт инде,— дип, мине нык кына кызартты.

Мин чемоданнарны арбаның бер як үрәчәсенә сөябрәк салдым да алар белән янәшәләп үзем дә утырдым.

Юл буенча Ногман бернәрсә дә сөйләшмәде. Мин генә, хатынның тормышына кагылырдай сораулар биргәләп, аның яшь кенә көе тол яшәвен, исеменең Фәрихә икәнлеген белеп алдым.

Бер урында тау менәсе булгач, без төшеп җәяүләдек, Фәрихә, ат тотучы булганлыктан, арбадан төшмәде. Көн бик эссе иде, Ногман кесәләрендәге барлык әйберләрен бушатып чалбар кесәсенә тутырды да өстен салып арбага илтеп куйды.

Тауны менеп җиткәч тә, икебез дә арбага менеп утырдык. Ат юырта башлагач, Ногман аякларын күтәреп арба читенә елышты. Фәрихә дилбегәне тарткан саен, ат, соры тузаннар туздырып, чапты да чапты.

Бераздан безнең авыл күренде.

Без авылга килеп җиттек.

Фәрихә, мин бик кыстасам да, чәй эчәргә дә кермәде, гадәттәгедән дә ныграк куа-куа, бик кызу китеп барды. Без өйгә кердек. Күрешү, ыгы-зыгы

китте. Шул вакытта ике кулын да чалбар кесәләренә батырган Ногман кычкырып җибәрде:

- Слуши, Сәлим! Минем акча да, документлар да юк бит!

Өй эчендәгеләр дә, мин дә аптырап калдык. Бу ни хәл бу?

Чынлап та Ногман хаклы булды микәнни? Төрлечә уй йөртү, кычкырып сөйләшү китте. Мин: «Бәлки, чалбар кесәңнән арбага шуып төшеп калгандыр, табылмасмы әле»,— дип, Ногманны өметләндерергә тырышып карадым. Ногман миңа каты итеп җавап бирде:

- Бар, эт авызына кергән сөякне алып кара хәзер. Алыр сың, табарсың!

Нәкъ шул вакытта ишек төбендә Фәрихә күренде. Кап-кара күзләрендә шелтә чагылдырып, Ногманга текәлде:

- Мәгез әйберләрегезне. Бигрәк каты әйтәсез икән. Алай таралып йөрергә ярамый. Әле яхшы, арба төбе тишек булмаган. Хушыгыз.

Ногман гүя телен йотты, хәтта «рәхмәт» дип тә әйтә алмады, аның битенә куе кызыллык йөгергән иде. (489 сүз)

5. ***Лексикология темасына диктант***

**Аналар һаман юксына.**

Хәтер... Ана тәрәзә янына баскан да тирән уйга чумган... Ул иң чиста, иң матур күлмәген кигән, башына бизәкле ак яулыгын бәйләгән, гәрәбә муенсасын таккан. Дивардагы сәгать вакытны саный. Алтмыш дүрт ел буена минутларны һәм сәгатьләрне барлый ул. Өстәлдә саргайган өчпочмаклы солдат хатлары ята. Диварда улының рәсеме эленеп тора. Ананың баласыннан шушы кадерле истәлекләр генә калган.

Хәсрәтле уйларга талган, хәтер диңгезендә йөзә ана. Улының фронтка киткәнен бүгенгедәй хәтерли ул.

Әнә, чаналы ат, урамны артта калдырып, каршыдагы сөзәк тауга менгән юлга чыкты. Егет ашыкмый гына чана артыннан атлый. Туктый да, авылына

борылып, яңгыравыклы тавыш белән җырлап җибәрә: «Бу китүдән кайта алмасак, сау булыгыз, туганнар!» Ана бу җырны көн саен күңеленнән көйли.

Әйе, аналар күңеле беркайчан да картаймый. Ул, еллар үткән саен, һаман нечкәрә һәм сафлана гына бара. Аналарның хәтерләре дә кайнап типкән чишмә башы кебек. *(133 сүз.) (К. Тәхаветдиновтан)*

***Бирем.***

***1 вариант. Чиста, кебек, кадерле сүзләренең синонимнарын табып язарга.***

***2 вариант. Хәсрәтле, истәлекләр, ашыкмый сүзләренең синонимнарын табып язарга.***

**6. Йомгаклау арадаш аттестация эше (*диктант)***

## Алиш белән очрашу.

Тагын бераздан безнең түгәрәккә Язучылар берлегеннән ярдәмгә даими шеф та билгеләделәр. Бу кеше Абдулла Алиш иде. Бу вакытта мин, зурдан кубып, завод уйлап табучылары турында повесть язарга керештем. Алиш катнашкан утырышларның берсендә бу әсәремнән бер өзек укыдым. Хәзер аңлыйм: әлбәттә, ифрат шәфкатьле шефыбыз бу эшне мине дәртләндерү өчен эшләгәндер. Әмма шунысы хак: ул мине үтереп мактады. “Мин бу иптәш әсәрен укыганда ук кул чапмакчы идем, тик аны бүлдерәсем килмәде”,- диде. Аның шул сүзләреннән соң минем күңелем күкнең җиденче катына очты, һәм мин һәр буш вакытымны повестька багышладым. Абдулла Алишның кара хәтфәдәй күзләре, тыныч йөз-кыяфәте, икегә ачып таралган чәчләре – барысы да бүгенгедәй күз алдында. Урта буйлы, нык бәдәнле, матур кеше иде. Беркайчан да чыгарыннан чыкмас, һәрнәрсәне тулы һәм ачык итеп аңлатыр. Мин аның үзенчәлекле яңгыравык тавышын да ачык хәтерлим. (128 с.)

## Эшне бәяләү системасы

Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаса «5» ле куела.(1-орфографик, 2 пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2 орфографик, 2 пунктуацион яки 1 орфографик, 4 пункт. хаталы эшкә «4» ле куела.
4 орфографик, 4 пунктуацион яки 3 орфографик, 6 пункт. хаталы эшкә «3» ле куела.
6 орфографик, 5 пунктуацион яки 5 орфографик, 8 пунк. хаталы эшкә «2» ле куела.